БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 03 2021 ел № 120

**«Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 185 номерлы һәм «Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 186 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 28 декабрендәге 2963-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 185 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта нигезендә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.
2. «Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 186 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта нигезендә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 19 мартыннан - Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек режимын кертү датасыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның 18 мартында
120 номерлы карарына
1 нче кушымта

1. Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче, Татарстан Республикасы милкендәге дәүләт мөлкәтен (алга таба - дәүләт мөлкәте) арендалау шартнамәләре буенча арендага алучылар мөрәҗәгать иткән көннән җиде көн эчендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) түбәндәге шартларда Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән аренда түләүләрен түләүне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешүләр төзүне:

кичектерү 2020 елның 1 апреленнән 2021 елның 1 гыйнварына кадәр, ә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә аренда түләүләрен түләүдән азат ителгән арендага алучылар өчен - 2020 елның 1 июленнән 2021 елның 1 гыйнварына кадәр бирелә:

аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнергә тиеш түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләве күләменең яртысыннан артмый торган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки арендага алучы тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм вакытын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендага алучы тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

б) «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестры турында» 2020 елның 23 июнендәге 906 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестрына һәм (яисә) «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында иң күп зыян күргән

коммерциягә карамаган оешмалар реестры турында» 2020 елның 11 июнендәге 847 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында иң күп зыян күргән коммерциягә карамаган оешмалар реестрына кертелгән оешмалар (алга таба - социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар) белән түбәндәге шартларда 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертү турында карар кабул итүгә кадәр төзелгән аренда шартнамәләренә аренда түләүләрен түләүне кичектерүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү:

кичектереп тору, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы күрсәтмәсе белән каралган аренда түләвеннән азат итүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган чорга бирелә;

социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма тарафыннан «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеге буенча (алга таба - Исемлек) бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баруына, шулай ук Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булган икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре турындагы 2020 елның 1 апреленә булган мәгълүматка карамастан, кичектереп тору бирелә;

аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнергә тиеш түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләве күләменең яртысыннан артмый торган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки арендага алучы тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм вакытын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендага алучы тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

в) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми http://www.baltasi.tatarstan.ru сайтында әлеге карар үз көченә кергән көннән җиде эш көне эчендә арендага алучыларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар өчен әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчалары нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Аренда түләүләрен кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә Татарстан Республикасы дәүләт казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча узган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган, әлеге карарның 1 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән арендага алучыларга бирелә дип билгеләргә. Аренда шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә, аренда түләве буенча бурыч бер тапкыр түләнә.

3. Башкарма хакимият органнарына, шулай ук алар карамагындагы муниципаль предприятиеләренә һәм муниципаль учреждениеләренә, арендага алучылары булып Исемлек буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар торган, 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча, Исемлекнең бер яисә берничә тармагында эшчәнлекне гамәлгә ашыруга, шулай ук Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә булган икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре турындагы мәгълүматка карамастан, 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү турында карар кабул ителгәнчегә кадәр төзелгән шартнамәләр буенча, түбәндәге шартларда аренда түләвен кичектереп торырга:

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына - 2020 елның 1 апреленнән 2021 елның 1 гыйнварына кадәр;

социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар - Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган чорга;

аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнергә тиеш түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләве күләменең яртысыннан артмый торган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки арендага алучы тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен

һәм вакытын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендага алучы тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне арендага бирүче тарафыннан билгеләү рөхсәт ителми;

кичектереп торуны күздә тоткан аренда шартнамәләренә өстәмә килешүләр арендага алучының тиешле мөрәҗәгате кергән көннән соң җиде эш көне эчендә төзелергә тиеш;

кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә дәүләт милкәтен арендалау шартнамәләре буенча узган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган арендага алучыларга бирелә.

4. Аренда түләвен түләүне кичектереп торуны бирү шартлары мондый килешү төзү датасына бәйсез рәвештә кичектерү турында өстәмә килешүләргә карата кулланыла дип билгеләргә.

5. Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның үтәлеше турында мәгълүматны билгеләнгән вакытта бирүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның 18 мартында
120 номерлы карарына
2 нче кушымта

1. Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче, Татарстан Республикасы милкендәге дәүләт мөлкәтен (алга таба - дәүләт мөлкәте) арендалау шартнамәләре буенча арендага алучылар мөрәҗәгать иткән көннән җиде көн эчендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеге буенча (алга таба - Исемлек) бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары (кече һәм урта эшкуарлык субъектлары ) белән 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән аренда шартнамәләренә аренда түләүләрен түләүдән азат итү турында өстәмә килешүләр төзү.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектына аренда түләүләрен түләүдән азат итү 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 июленә кадәр бирелә.

Арендага алучы - кече һәм урта эшкуарлык субъекты Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында яисә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә мәгълүматы булган икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендага бирүне күздә тоткан аренда шартнамәләренә, аны Исемлек буенча икътисадый эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдалану максатларында һәм әлеге төр эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен күрсәтелгән мөлкәттән файдалануны раслаучы документлар булганда төзелә;

б) «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестры турында» 2020 елның 23 июнендәге 906 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестрына һәм (яисә) «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында иң күп зыян күргән

коммерциягә карамаган оешмалар реестры турында» 2020 елның 11 июнендәге 847 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында иң күп зыян күргән коммерциягә карамаган оешмалар реестрына кертелгән оешмалар (алга таба - социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар) белән Исемлекнең бер яисә берничә тармагында эшчәнлекне гамәлгә ашыруга, шулай ук Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә булган икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре турындагы мәгълүматка карамастан, 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертү турында карар кабул итүгә кадәр төзелгән аренда шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән аза итү турында өстәмә килешүләр төзү.

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларны аренда түләүләрен түләүдән азат итү 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 июленә кадәр башкарыла;

в) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми http://www.baltasi.tatarstan.ru сайтында әлеге карар үз көченә кергән көннән җиде эш көне эчендә арендага алучыларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар өчен әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчалары нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Әлеге карар нигезендә аренда түләүләрен түләүдән азат итү Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә Татарстан Республикасы дәүләт казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча узган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендага алучыларга бирелә дип билгеләргә.

3. Аренда түләүләреннән азат итү шартлары аренда шартнамәләренә өстәмә килешүләр төзү датасына бәйсез рәвештә кулланыла.

4. Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның үтәлеше турында мәгълүматны билгеләнгән вакытта бирүне тәэмин итәргә.